КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 май г.Казань № 296

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика күзәтүе формаларын, социологик тикшеренүләр исемлеген һәм социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат материаллары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 28 гыйнвар, 32 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика күзәтүе формаларын, социологик тикшеренүләр исемлеген һәм социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат материаллары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 28 гыйнвар, 32 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 апрель, 228 нче; 2021 ел, 16 август, 724 нче; 2022 ел, 26 гыйнвар, 49 нчы, 2023 ел, 2 март, 197 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

түбәндәге республика күзәтүенең формаларын:

1-ӨК (квартал) «Предприятиенең өстәлгән кыйммәте турында мәгълүматлар»;

1-инвест-терк (квартал) «Чит илләрдән инвестицияләр турында мәгълүматлар»;

1-РГП (ЮЗ) (квартал) «Эшмәкәрлеккә һәм/яки ярдәм алучыларга ярдәм күрсәтү инфраструктурасы объектлары резиденты-предприятиеләре эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында мәгълүматлар»;

1-РГП (ИЭ) (квартал) «Эшмәкәрлеккә һәм/яки ярдәм алучыларга ярдәм күрсәтү инфраструктурасы объектлары резиденты-индивидуаль эшмәкәрләре эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында мәгълүматлар»;

3-фермер (кыска) (квартал) «Терлекчелек продукциясе җитештерү, терлек һәм кош-корт саны турында мәгълүматлар»;Par1089

7-ВЭС (еллык) «Товарлар экспорты турында мәгълүматлар»;

14-мет (ватыклар)-р (бер тапкыр бирелә торган) «Кара һәм төсле металл ватыклары барлыкка килү, аларны хәзерләү һәм файдалану турында мәгълүматлар»;

24-АХ (МП) (еллык) «Терлекчелек торышы турында мәгълүматлар»;Par1823

1-ЭА (бер тапкыр бирелә торган) «Эшмәкәрлек проблемаларын өйрәнү анкетасы»;

СҖИ (айлык) «Сәнәгать җитештерүе индекслары»;

П-1 (АХ)-р (айлык) «Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм төяп җибәрү турында мәгълүматлар»;

КП-р (квартал) «Кече предприятие эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында мәгълүматлар»;

«1-ӨК (ярты еллык) «Россия Федерациясе төбәкләреннән, чит илләрдән кертелә торган чимал һәм материаллар, комплектлау әйберләре, ярымфабрикатлар, ягулык-энергетика ресурслары (ЯЭР) турында мәгълүматлар» формасына кушымта;

1-инвестиция-фараз (квартал) «Төп капиталга инвестицияләрнең фаразлау күрсәткечләре турында мәгълүматлар»;

1-төзелеш (фараз) (айлык) «Предприятиенең фаразлау күрсәткечләре турында мәгълүматлар»;

түбәндәге социологик тикшеренүләр исемлеген:

«Татарстан Республикасында коррупция («көнкүреш») турында халык фикерен өйрәнү»;

«Татарстан Республикасы халкының финанс белемен өйрәнү»;

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатыннан гражданнарның гомуми канәгатьлелеген тикшерү»;

«Татарстан Республикасында халыкның формаль булмаган эш белән тәэмин ителеше»;

«Татарстан Республикасында күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатыннан халыкның канәгать булуы турында»;

«Татарстан Республикасында «эшлекле» коррупция дәрәҗәсе турында»;

«Татарстан Республикасында дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегеннән халыкның канәгатьлек дәрәҗәсе турында, шулай ук дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәтнең нәтиҗәлелеге һәм абруе турында»;

«Татарстан Республикасында кара һәм төсле металл ватыкларын әзерләүне, саклауны, эшкәртүне һәм сатуны гамәлгә ашыручы предприятиеләрне лицензияләү хезмәте сыйфатын бәяләү»;

2024 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең республика башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» исәп-хисап системасында яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурында «Мәгълүмати статистик ресурс» рубрикасында https://ias.tatar.ru. адресы буенча урнаштырыла торган социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча белешмә материаллар исемлеге.»;

түбәндәге эчтәлекле 31 пункт өстәргә:

«3[1]. Республика башкарма хакимият органнарына:

«Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» хисаплылыкның бердәм дәүләт системасында, https://ias.tatar.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурларында «Мәгълүмати статистика ресурсы» рубрикасында социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча урнаштырыла торган мәгълүмат материалларыннан файдаланып, җирле үзидарә органнарыннан, хуҗалык итүче субъектлардан соратып алынган мәгълүмат санын киметергә;

ведомство статистик хисаплылык рәвешләрен эшләгәндә һәм керткәндә күрсәтелгән формаларны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килештерү процедурасын үткәрергә.»;

әлеге карар белән расланган «Эшмәкәрлек проблемаларын өйрәнү буенча анкета» 1-АП номерлы (бер тапкыр) республика күзәтү формасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

әлеге карар белән расланган «Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм төяп җибәрү турында белешмәләр» П-1 (СХ)-р (айлык) республика күзәтүенең формасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

әлеге карар белән расланган 2023 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» исәп-хисап системасында яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурында «Мәгълүмати статистик ресурс» рубрикасында https://ias.tatar.ru. адресы буенча урнаштырыла торган социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат материаллары исемлеген яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә; https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=172657&dst=102634

әлеге карарга «Предприятиенең фараз күрсәткечләре турында белешмәләр» 1-төзелеш (фараз) (айлык) республика күзәтүе формасы белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=163111&dst=102534&field=134&date=22.02.2024

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 гыйнвар, 32 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 6 май, 296 нчы карары редакциясендә)

№ 1-АП формасы (бер тапкыр)

Эшмәкәрлек проблемаларын өйрәнү буенча анкета

Татарстан  Республикасы Икътисад министрлыгы эшмәкәрлекнең җитештерү, финанс, икътисадый һәм башка проблемаларын тикшерү максатларында тәкъдим ителә торган сорауларга җавап бирүегезне сорый. Сезнең тарафтан әлеге куелган мәсьәләләргә карата кызыксынуыгыз булыр дип уйлыйбыз. Барлык сорауларга җавап бирүегезне һәм анкетаны игътибар белән тутыруыгызны сорыйбыз (галочка белән билгеләгез яки җавапның кирәкле вариантын түгәрәк белән әйләндереп алыгыз).

1 бүлек. Гомуми мәгълүмат

1. Сез кем булуыгызны күрсәтегез, зинһар. Җавапның бер вариантын билгеләгез.
1.1. Юридик зат.
1.2. Шәхси эшмәкәр.
1.3. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллана торган физик зат (үзмәшгуль).

2. Үз эшчәнлегегезнең төп төрен күрсәтегез, зинһар. Җавапның бер вариантын билгеләгез.
2.1. Сәнәгать производствосы.
2.2. Авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык һәм балык үрчетү.
2.3. Төзелеш.
2.4. Башкасы (языгыз)________________

3. Үз бизнесыгыз эшчәнлегенең төп төре өчен Сез салым салуның нинди системасын кулланасыз? Җавапның бер вариантын билгеләгез.
3.1. Салым салуның гадиләштерелгән системасы.
3.2. Салым салуның гомуми системасы.
3.3. Салым салуның патент системасы.
3.4. Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы.
3.5. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә салым салу системасы (ЕСХН).
3.6. »Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимы.

3.7. Башкасы (языгыз)________________
3.8. Җавап бирергә кыенсынам.

4. Зинһар, Сезнең җенесне күрсәтегез (юридик затларга җитәкченең җенесен күрсәтергә кирәк):
4.1. Хатын-кыз.
4.2. Ир-ат.

5. Зинһар, Үзегезнең яшегезне күрсәтегез (юридик затларга җитәкченең яшен күрсәтергә кирәк)
:
5.1. 18 яшьтән 25 яшькә кадәр.
5.2. 25 яшьтән 35 яшькә кадәр.
5.3. 36 яшьтән 44 яшькә кадәр.
5.4. 45 яшьтән 49 яшькә кадәр.
5.5. 50 яшьтән 59 яшькә кадәр.
5.6. 60 яшьтән һәм өлкәнрәк.

## 2 бүлек. Икътисадый вәзгыятьне бәяләү

6. Сез Татарстан Республикасында һәм сезнең муниципаль берәмлектә гомуми икътисадый хәлне ничек бәялисез? һәр багана буенча җавапның бер вариантын билгеләгез.

| Икътисадый вәзгыятьне бәяләү | 6.1. Татарстан Республикасы | 6.2. Муниципаль районы |
|---|---|---|
| Яхшырды | 6.1.1. | 6.2.1. |
| Үзгәрешләрсез калды | 6.1.2. | 6.2.2. |
| Начарланланды | 6.1.3. | 6.2.3. |

7. Әгәр дә Сез икътисадый хәлнең начараюын билгеләсәгез, бу Сезнең эшчәнлектә нәрсәгә йогынты ясавын күрсәтегез. Җавапның, күпме кирәк дип саныйсыз, шулкадәр вариантларын билгеләгез.
7.1. Товарларга/эшләргә/хезмәтләргә ихтыяҗ кимү.
7.2. Товарларга/эшләргә/хезмәтләргә ихтыяҗ арту.
7.3. Сатып алына торган чимал/материалларга бәяләр үсеше, димәк, продукциянең үзкыйммәте үсеше.
7.4. Чит ил җиһазларын һәм запас өлешләрен, чималны, материалларны һ.б. сатып алуга чикләүләр.
7.5. Россия базарында элек сатып алына торган чит ил җиһазларының һәм запас частьләрнең, чимал, материалларның аналоглары булмау һ.б.
7.6. Җитештерелә торган продукцияне экспортлау буенча чикләүләр.
7.7. Гамәлдәге кредит шартнамәләре буенча шартларны үзгәртү, процент ставкаларының үсүе.

7.8. Гамәлгә ашырыла торган товарның бәясен арттыруга чикләүләр булу (үзкыйммәтен үстерү шарты белән).

7.9. Дус булмаган илләрдән җитештерүчеләр импортын чикләү исәбенә конкуренциянең кимүе.

7.10. Җитештерүне базарда ихтыяҗ булган продукциянең башка төренә үзгәртү.

7.11. Эшчәнлекне туктату.

7.12. Предприятиенең финанс тотрыклылыгы начараю.

7.13. Заем акчаларын алуда кыенлыклар, ярдәм итүнең финанс чаралары.

7.14. Әзер продукция запасларын кыскарту.

7.15. Җитештерү (мөрәҗәгать итү) чыгымнарының артуы.

7.16. Хезмәткәрләр санын кыскарту.

7.17. Башкасы (языгыз)________________

8. Сез чыгара торган продукция яисә күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләме узган ел белән чагыштырганда ничек үзгәрде? Җавапның бер вариантын билгеләгез.

8.1. Артты.

8.2. Үзгәрешләрсез калды.

8.3. Кимеде.

9. Сез соңгы елда сатып алучылар / клиентлар өчен Сезнең продуктларга / хезмәтләргә бәяләрне ничек үзгәрттегез? Җавапның бер вариантын билгеләгез.

9.1. Бәяләр күтәрделәр.

9.2. Бәяләр төште.

9.3. Үзгәрешләрсез калдырдылар.

## 3 бүлек. Ярдәм чаралары

10. Сезнең карашка, нәтиҗәле эшчәнлектән тыш, агымдагы икътисадый ситуациядә кече һәм урта бизнесны алга таба үстерү өчен нәрсә кирәк? Җавапның иң күбе биш вариантын билгеләгез.

10.1. Эшмәкәрләр эшчәнлеген законнар-нормативлар белән тәэмин итү.

10.2. Салым йөкләнешенең кимүе.

10.3. Конкуренция өчен тигез мөмкинлекләр булдыру.

10.4. Дәүләт финанс ярдәме күрсәтү.

10.5. Импортны алыштыру кысаларында эшчәнлек алып баручы предприятиеләргә дәүләт ярдәме (җиһазларны модернизацияләү, персоналны укыту һ.б.).

10.6. Җәмгыятьтә эшмәкәрләрнең уңай имиджын булдыру һәм аларга ярдәм күрсәтү.

10.7. Кече һәм урта эшмәкәрлек (алга таба - КУЭ) субъектларына (саны һәм әйләнеше буенча) кертү күрсәткечләре буенча чик күрсәткечләрен арттыру.

10.8. Башкасы (языгыз)________________

11. Сез беләсезме, хакимият тарафыннан бизнеска ярдәм итү чаралары турында беренче тапкыр ишеттегезме яки ишетәсезме?

11.1. Яхшы беләм.

11.2. Нәрсәдер ишеттем. 14.1 сораугa күчү
11.3. Беренче тапкыр ишетәм. 14.2 сораугa күчү

12. Сез бизнеска ярдәм итү чараларыннан файдаланасызмы? Җавапның бер вариантын билгеләгез.
12.1. Әйе. 14 сораугa күчү
12.2. Юк, планлаштырам.
12.3. Юк.

13. Кулланмасагыз, нигә?
13.1. Ярдәм чаралары һәм аларны алу процедурасы турында мәгълүмат җитәрлек түгел.
13.2. Ярдәм чаралары туры килми.
13.3. Предприятие эшчәнлеге төре бизнеска ярдәм итү чараларына эләкми.
13.4. Предприятиенең формасы ярдәм чараларын алуны күздә тотмый.
13.5. Ярдәм чараларын алу процедурасы сроклары дәвамлылыгы.
13.6. Ярдәм чаралары алганда бюрократик кыенлыклар.
13.7. Бизнеска ярдәм чараларын бирүдән баш тарттылар.
13.8. Кирәге юк.
13.9. Башкасы (языгыз)________________

14. Хакимият тарафыннан бизнеска ярдәм итүнең нинди чаралары турында Сез хәбәрдар, нинди чаралар белән файдаланырга теләсәгез яки инде файдалансагыз һәм нинди чаралар иң нәтиҗәле дип саныйсыз? Һәр багана буенча җавапның, күпме кирәк дип саныйсыз, шулкадәр вариантларын билгеләгез.

| Бизнеска ярдәм чаралары | 14.1. Бизнеска ярдәм итүнең нинди чаралары турында Сез беләсез яки нәрсәдер ишеттегез? Җавапның, күпме кирәк дип саныйсыз, шулкадәр вариантларын билгеләгез. | 14.2. Бизнеска ярдәм итүнең нинди чаралары белән файдаланырга теләр идегез? Җавапның, күпме кирәк дип саныйсыз, шулкадәр вариантларын билгеләгез. | 14.3. Бизнеска ярдәм итүнең нинди чаралары белән Сез инде файдаландыгыз? Җавапның, күпме кирәк дип саныйсыз, шулкадәр вариантларын билгеләгез. | 14.4. Сез бизнеска ярдәм итүнең нинди чараларын иң нәтиҗәле дип саныйсыз? Җавапның, күпме кирәк дип саныйсыз, шулкадәр вариантларын билгеләгез. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фондының ташламалы займнары, микрозаймнары | 14.1.1 | 14.2.1 | 14.3.1 | 14.4.1 |
| Татарстан Республикасы Гарантия фондының ташламалы поручительлеге | 14.1.2 | 14.2.2 | 14.3.2 | 14.4.2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 3. Социаль эшмәкәрләр реестрына кертелгән МСП грантлары яисә 25 яшькә кадәрге физик затлар тарафыннан төзелгән МСП субъектлары | 14.1.3 | 14.2.3 | 14.3.3 | 14.4.3 |
| 4. Товарларны маркетплейсларда, шул исәптән халыкара маркетплейсларда урнаштыруны тәэмин итү | 14.1.4 | 14.2.4 | 14.3.4 | 14.4.4 |
| 5. Продукцияне сертификацияләү | 14.1.5 | 14.2.5 | 14.3.5 | 14.4.5 |
| 6. Россия Федерациясе территориясендә һәм чит илләрдә күргәзмә-ярминкә чараларында катнашу | 14.1.6 | 14.2.6 | 14.3.6 | 14.4.6 |
| 7. Продукция/ хезмәтләр рекламасы | 14.1.7 | 14.2.7 | 14.3.7 | 14.4.7 |
| 8. Предприятиеләрнең бизнес-планнарын эшләү | 14.1.8 | 14.2.8 | 14.3.8 | 14.4.8 |
| 9. Сәнәгать (индустриаль) паркларында урнаштыру | 14.1.9 | 14.2.9 | 14.3.9 | 14.4.9 |
| 10. Уку программаларын узу | 14.1.10 | 14.2.10 | 14.3.10 | 14.4.10 |
| 11. Икенче (язызыз) ____________ | 14.1.11 | 14.2.11 | 14.3.11 | 14.4.11 |

15. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү инфраструктурасының нинди оешмалары хезмәтләреннән Сез файдаланасыз? Җавапның, күпме кирәк дип санийсыз, шулкадәр вариантларын билгеләгез.

15.1. »МСП» цифрлы платформасы.

15.2. Технопарк.

15.3. Индустриаль (сәнәгать) парк.

15.4. «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе:

а) Микрофинанслау үзәге;

б) «Минем бизнес» үзәге;

в) Экспортка ярдәм үзәге.

15.5. «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешмасы.

15.6. «Татарстан Республикасының Төбәк лизинг компаниясе» акционерлык җәмгыяте.

15.7. «Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

15.8. «Татарстанның республика маркетинг үзәге» биржа мәйданчыгы (алга таба - РМҮ).

15.9. «Фәнни-техник өлкәдә предприятиеләрнең кече формаларын үстерүгә булышлык күрсәтү фонды» федераль дәүләт бюджет учреждениесе.

15.10. »Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыяте.

15.11. Кулланмыйбыз. 18 сорауга күчү

15.12. Башкасы (языгыз)________________

16. Әгәр дә сез инвестиция инфраструктурасы объекты (технопарк, индустриаль (сәнәгать) паркы резиденты булсагыз, зинһар өчен, 5 баллы шкала буенча (иң яхшы бәяләү - 5 балл, иң начары - 1 балл):

| Т/с | Критерийлар | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 16.1. | Инвестиция инфраструктурасы объектларында урыннарның һәркем файдалана алырлык булуы | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 16.2. | Күрсәтелә торган ярдәм чараларының нәтиҗәлелеге һәм инвестиция инфраструктурасы объектлары резидентлары өчен күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

17. Кече һәм урта бизнеска ярдәм инфраструктурасы оешмаларына (15 пунктта санап үтелгән) 5 баллы шкала буенча (иң яхшы бәяләү - 5 балл, иң начары - 1 балл) ярдәм итүнең консультация, мәгариф хезмәтләре күрсәтү сыйфатын һәм (яисә) финанс чараларын күрсәтүне бәяләгез:

| Т/с | Критерийлар | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 17.1. | Консультация һәм (яисә) мәгариф хезмәтләре күрсәтү өчен җаваплы персоналның квалификациясе | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 17.2. | Консультатив һәм (яисә) белем бирү программаларында катнашу мөмкинлеге, шул исәптән онлайн | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 17.3. | Ярдәмнең финанс чараларын бирү сыйфаты | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

18. Сезнең мөлкәт ярдәменә ихтыяҗыгыз бармы? Җавапның бер вариантын билгеләгез.

18.1. Әйе, ташламалы аренда шартларында мөлкәткә ихтыяҗ бар.

18.2. Әйе, резидент сыйфатында сәнәгать паркы территориясендә урнаштыру ихтыяҗы бар.

18.3. Юк, ташламалы аренда шартларында мөлкәттән файдаланам инде / сәнәгать паркы резиденты булып торам.

18.4. Юк.

19. Сез Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы (алга таба - Агентлык) эшчәнлеге белән танышмы?

19.1. Әйе (таныш/мөрәҗәгать иттем).

19.2. Юк. 21 сорауга күчү

20. 5 баллы шкала буенча Агентлык эшчәнлеген бәяләгез (иң яхшы бәяләү - 5 балл, иң начары - 1 балл):

| Т/с | Критерийлар | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 20.1. | Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән инвесторларга һәм башка сервис/хезмәтләргә консультация ярдәменең сыйфаты | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 20.2. | Агентлык хезмәткәрләренең квалификациясе | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 20.3. | Сез Агентлыкка мөрәҗәгать иткән мәсьәләне хәл итү дәрәҗәсе | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

21. Сез Татарстан Республикасы Инвестиция Советы (алга таба - Совет) эшчәнлеге белән танышмы?

21.1. Әйе.

21.2. Юк. 23 сорауга күчү

22. Соңгы 12 айда Совет эшенең нәтиҗәлелегеннән сез ни дәрәҗәдә канәгать? 5 баллы шкала буенча бәяләгез (иң яхшы бәяләү - 5 балл, иң начары - 1 балл):

| Т/с | Критерийлар | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 22.1. | Совет утырышларының ачык булуы | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 22.2. | Эшмәкәрләрнең инвестицион климатны яхшырту буенча үз инициативаларын күрсәтү мөмкинлеге бар | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 22.3. | Совет тарафыннан эшкуарлар тәкъдим иткән инициативаларны карау | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

23. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының бизнеска ярдәм итү эшчәнлеген сез ничек бәялисез? 5 баллы шкала буенча бәяләгез (иң яхшы бәяләү - 5 балл, иң начары - 1 балл):

| Т/с | Орган исеме | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 23.1. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, шул исәптән: | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 23.1.1. | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

| Т/с | Орган исеме | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 23.1.2. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 23.2. | Сезнең муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

24. Әгәр алдагы сорауда Сез республика дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә түбән бәя биргән булсагыз (1, 2, 3 билгеләре), сәбәпләрен күрсәтегез: _______________________________

4 бүлек. Эшчәнлек алып бару шартлары

25. Сезнең банкларда гамәлдәге кредитларыгыз бармы? Җавапның бер вариантын билгеләгез.

25.1. Әйе, бар. Кредит түләү белән проблемалар юк.
25.2. Әйе, бар. Кредит түләү белән проблемалар бар.
25.3. Юк, әмма рәсмиләштерергә планлаштырам.
25.4. Юк, рәсмиләштерергә теләдем, ләкин булдыра алмадым.
25.5. Юк, рәсмиләштерергә планлаштырмыйм.

26. Төбәктә юл челтәренең сыйфатын (аерым алганда, сезнең муниципаль районда) 5 баллы шкала буенча бәяләгез (иң яхшы бәяләү - 5 балл, иң начары - 1 балл):

| Т/с | Критерийлар | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 26.1. | Бизнес алып бару өчен яраклы юл полотносының сыйфаты | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 26.2. | Сезнең бизнес өчен автомобиль транспорты белән вакытында илтеп җиткерү мөмкинлеге | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

27. Сезнең бизнес алып бару өчен телекоммуникация хезмәтләре сыйфатын 5 баллы шкала буенча бәяләгез (иң яхшы бәяләү - 5 балл, иң начары - 1 балл):

| Т/с | Критерийлар | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 27.1. | Мобиль бәйләнеш (өслек, тотрыклы эш һ.б.) | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 27.2. | Интернет-элемтә (өслек, эш тотрыклылыгы, тизлеге) | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

28. Сезнең бизнесны кадрлар белән тәэмин итүдә проблемалар бармы? Җавапның бер вариантын билгеләгез.

28.1. Әйе.
28.2. Юк.

5 бүлек. Продукция һәм хезмәтләр сату базарлары

29. Сезнең продукциягез сатыла торган сату базарларын, өлешне күрсәтеп, билгеләгез:

29.1. Муниципаль  район – __%.
29.2. Татарстан Республикасы – __%.
29.3. Россия Федерациясенең башка төбәкләре - ___%.
29.4. Экспорт - ___%.

30. Сезнең продукцияне җитештерү өчен чимал, материаллар һәм комплектлау әйберләре сатып алына торган сатып алулар базарларын билгеләгез, өлешне күрсәтеп:
30.1. Муниципаль  район – __%.
30.2. Татарстан Республикасы – __%.
30.3. Россия Федерациясенең башка төбәкләре - ___%.
30.4. Импорт - ___%.

31. Сез соңгы 12 айда дәүләт (муниципаль) сатып алуларында катнаштыгызмы? Җавапның бер вариантын билгеләгез.
31.1. Әйе.
31.2. Юк.

32. Сез Татарстан Республикасының Дәүләт заказы агентлыгы тарафыннан төзелгән РМҮ барлыгы турында беләсезме?
32.1.  Әйе, кулланам.
32.2. Юк, бу ресурста сатып алулар һәм сатулар буенча эшләргә өйрәнергә телим.
32.3. Юк / кирәк түгел.

33. РМҮ («Импортны алыштыру үзәге» РМҮ, http://rmcrt.ru/) аша импортны алмаштыру мөмкинлеге турында беләсезме?/ Җавапның бер вариантын билгеләгез.
33.1. Әйе, ишеттем.
33.2. Юк, РМҮ аша импортны алыштыру мәсьәләсе буенча укырга кирәсем килә.
33.3. Юк / кирәк түгел.

34. Сез үз продукциягезне урнаштыру өчен нинди маркетплейслар кулланасыз? Җавапның, күпме кирәк дип санийсыз, шулкадәр вариантларын билгеләгез.
34.1. Wildberries (Вайлдберриз).
34.2. Ozon (Озон).
34.3. Яндекс. Маркет.
34.4. СберМегаМаркет.
34.5. KazanExpress (Казан Экспресс).
34.6. CDEK.Маркет.
34.7. AliExpress.
34.8. Башкасы (языгыз)________________
34.9. Кулланмыйм.

35. Әгәр маркетплейслар белән файдаланмасагыз, Сезгә товарлар урнаштыру һәм маркетплейсларда эшләү буенча укыту кирәкме? Җавапның бер вариантын билгеләгез.

35.1. Әйе.
35.2. Кирәге юк.

6 бүлек. Проблемалар һәм проблемаларны хәл итүдә ярдәм

36. Сезнең бизнесны үстерүне чикли яки тоткарлый торган проблемалар яки факторлар бармы?
36.1. Юк.
36.2. Әйе. Әлеге җавапны сайлаганда түбәндәге проблемаларны яисә факторларны күрсәтегез:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

37. Алдагы мәсьәләдә күрсәтелгән проблемаларны хәл итүдә ярдәм таләп ителәме?
37.1. Юк.
37.2. Әйе. Әлеге җавапны сайлаганда, нинди ярдәм кирәклеген күрсәтегез:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

_________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 гыйнвар, 32 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 6 май, 296 нчы карары редакциясендә)

№ П-1 (АХ)-р формасы
(айлык)

| |
|---|
| РЕСПУБЛИКА КҮЗӘТҮЕ |

| |
|---|
| КОНФИДЕНЦИАЛЬЛЕГЕ МӘГЪЛҮМАТ АЛУЧЫ ТАРАФЫННАН ГАРАНТИЯЛӘНӘ |

| |
|---|
| ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ КЕРТЕЛЕРГӘ МӨМКИН |
| **Error! Not a valid filename.**20 ____ елның ______________________ өчен<br>(ай) |

| Кертәләр: | Кертү вакытлары |
|---|---|
| авыл хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кече эшмәкәрлек субъектлары (кече һәм микропредприятиеләр) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы өчен Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына | Хисап чорыннан соң айның 3 есендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Хисап бирә торган оешма исеме | | | |
| Почта адресы | | | |
| Коды | | | |
| ОКПО буенча хисап бирә торган оешма (юридик затның территориаль аерым урнашкан бүлекчәләре һәм баш бүлекчәсе өчен – тәңгәлләштерелгән номеры) | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

## 1 бүлек. Авыл хуҗалыгы продукциясе хәрәкәте

ОКЕИ буенча кодлары: гектар – 059; центнер – 206; мең данә – 798

| Күрсәткеч исеме | Юл саны | ОКПД2 буенча коды | Хисап ае өчен | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | сабан культуралары чәчелде, җыелды (казып алынды)[1], гектар | җитештерелде, центнер | үз җитештерүендәге продукция төяп җибәрелде (тапшырылды), центнер | ай ахырына калдык, центнер |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| I. Үсемлекчелек<br>Бөртекле һәм кузаклы культуралар, кукуруздан башка: | | | | | | |
| башлангыч приходка алынган авырлыкта | 1 | 01.11.12.002* | | [1] | × | × |
| эшкәртелгәннән соң үлчәүдә | 2 | | | [1] | | |
| шул исәптән бодай:<br>башлангыч приходка алынган авырлыкта | 3 | 01.11.1 | | [1] | × | × |
| эшкәртелгәннән соң үлчәүдә | 4 | | | [1] | | |
| Кукуруз (ашлык өчен) | 5 | 01.11.20 | | [1] | | |
| Майлы культураларның орлыклары һәм җимешләре | 6 | 01.11.81.001* | | [1] | | |
| шул исәптән көнбагыш орлыклары | 7 | 01.11.95 | | [1] | | |
| Шикәр чөгендере | 8 | 01.13.71.100 | | [1] | | |
| Сүс җитене | 9 | 01.16.19.111 | | × | | |
| Бәрәңге | 10 | 01.13.51 | | [1] | | |
| Яшелчәләр ачык грунт | 11 | 01.13.01.101* | | [1] | × | × |
| ачык һәм ябык грунт | 12 | 01.13.01.001* | × | [2] | | |
| II. Терлекчелек<br>Сугым өчен терлек һәм кош-корт (тере үлчәмдә) | 13 | 01.41.47.001* | × | | | |
| шул исәптән:<br>мөгезле эре терлек | 14 | 01.42.11.130 | × | | | |
| дуңгызлар | 15 | 01.46.10.500 | × | | | |
| сарыклар һәм кәҗәләр | 16 | 01.45.11.400 | × | | | |
| барлык төрдәге кош-корт | 17 | 01.47.12.001* | × | | | |
| терлекнең башка төрләре (атлар, боланнар һ.б.) | 18 | 01.43.44.001* | × | | | |
| Мөгезле эре терлек сөте (кайнатылмаган) | 19 | 01.41.20 (01.41.20.190 дан тыш) | × | | | |
| шул исәптән сыер сөте | 20 | 01.41.20.110 | × | | × | × |
| Тавык йомыркалары (инкубация йомыркаларын кертеп), мең данә | 21 | 01.47.21.002* | × | | [4] | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сарык йоны[3] | 22 | 01.45.30.004* | × | | | |
| Тере үлчәүдә җитештерелде (үстерелде)[3]:<br>мөгезле эре терлек | 23 | 01.41.10.001* | | | | |
| дуңгызлар | 24 | 01.46.10.001* | × | | × | × |
| сарыклар һәм кәҗәләр | 25 | 01.45.12.001* | × | | × | × |
| барлык төрдәге кошлар | 26 | 01.47.12.001* | × | | × | × |

[1]Хисап аеның ахырына арта бара торган йомгак белән тутырыла.
Урып-җыю чорында, 1 июльдән 1 ноябрьгә кадәр:
4 графада 1, 3 юллар буенча – чабылды, га;
4 графада 2, 4 юллар буенча – суктырылды, гектар
[2] Ай саен хисап ае ахырына арта бара торган йомгак белән тутырыла.
[3]Гыйнвар – март, апрель – июнь, июль – сентябрь, октябрь – декабрь өчен тутырыла.
[4]Инкубация өчен сатылган йомыркаларны исәпкә алмыйча.
*ОКПД2 нең локаль кодлары.

## 2 бүлек. Терлек һәм кош-кортның баш саны, азыклар булу

ОКЕИ буенча кодлар: баш □ 836; азык берәмлеге □центнер 972

| Күрсәткеч исеме | Юл саны | Хисап ае ахырына |
|---|---|---|
| Терлек һәм кош-кортның баш саны, баш:<br>Мөгезле эре терлек | 27 | |
| шул исәптән сыерлар (ашытып һәм йөртеп симертүдә булган сыерлардан башка) | 28 | |
